КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 июль г.Казань № 581

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын, спорт чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 4 июль, 547 нче карары белән расланган Теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын, спорт чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын, спорт чараларын финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 4 июль, 547 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 19 ноябрь, 1012 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын, спорт чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 159 нчы карары белән расланган «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба – Министрлык) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

5 нче пунктның алтынчы абзацында татар текстында «үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык процессында тормаган» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормаган» сүзләренә алыштырырга, «ябылу процессында тормаган» сүзләреннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы башланмаган, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктның бишенче абзацында татар текстында «үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык процессында тормавын» сүзләрен «үзгәртеп оештыру, ябылу процессында тормавын» сүзләренә алыштырырга, «ябылу процессында тормавын» сүзләреннән соң «, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавын, эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын» сүзләрен өстәргә;

7 нче пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучы тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.»;

9 нчы пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәләре» сүзенә алыштырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

өстәмә хисаплылык вакытлары һәм формасы (кирәк булганда);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кирәк булганда, Министрлык коммерциягә карамаган оешма белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

11 нче пунктта:

беренче абзацта «Субсидия күләме» сүзләрен «Субсидия күләме (С)» сүзләренә алыштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

13 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү Министрлык тарафыннан субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең түбәндәге мәгънәләренә ирешүдән чыгып гамәлгә ашырыла:

спорт разрядлары һәм исемнәре булган спортчылар саны;

теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чаралары, спорт чаралары саны.»;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Коммерциягә карамаган оешмалар Министрлыкка субсидия бирү елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр бу Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

18 нче пунктның дүртенче абзацында «нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең» сүзләрен «нәтиҗәсенең» сүзенә алыштырырга;

19 нчы пунктта «14 һәм 17 нче пунктларында» сүзләрен «15 һәм 18 нче пунктларында» сүзләренә алыштырырга;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын, спорт чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 июль, 581 нче
карары редакциясендә))

Форма

2020 елның «___» ____________ы(е) хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап

Коммерциягә карамаган оешманың исеме: ______________________________

Тапшыру вакыты: ______________________________

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Проектның исеме (чаралар) | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификациясе буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәгә ирешү өчен кирәкле күрсәткечнең ирешелгән мәгънәләре | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсеннән тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

Коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе
(вәкаләтле зат) __________________ _________________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

Башкаручы ______________ _____________________________ ____________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (телефоны)

20__ , «__» ____________

________________________________